Минем һөнәри осталыгым

эссе

Балык Бистәсе муниципаль районы
“Балык Бистәсе 2нче номерлы гомуми урта
белем бирү мәктәбе” МГББУукытучысы
Токранова Эльвира Ильяс кызы

Һөнәр осталык... Үз һөнәреңнең остасы булу... Әлеге сүзләр үз эченә бик күп мәгънә сала. Бу сүзләрне әйткәндә, минем күз алдыма гомере буе бер өлкәдә эшләп, бөтен барлыгын шул һөнәренә биргән, ачышлар һәм табышлар бәрабәренә шәхси мәнфәгатьләрен корбан иткән чын шәхесләр килеп баса. Күренекле галим, олпат язучы, станок артында бил бөккән эшче, күктә күренгән болыт кисәгенә дә дошман яки дус итеп карарга мөмкин игенче... Сугыш вакытында, аннан соңгы авыр елларда ягылмаган салкын мәктәптә белем биреп күпме шәхесләрне тәрбияләгән бабам, әбием, дәү әнием, алардан юнәлеш алып гомер буе балалар укыткан әти-әнием дә- үз һөнәренең осталары. Бу осталык эш барышында бәяләнә алмый, вакытлар узгач, тормыш аңа үзе “билге куя”. “Мин сиңа үскәч күлмәк алам, апа!”-дигән сабыйның, ир уртасы булгач, сүзендә торуы; инде үзләре әби-бабай булган “укучыларының”, Сабантуй җиткәч, әби янына килүе...

Бездә бармы ул, һөнәри осталык? Ул олимпиада, конференцияләрдә чыгыш ясау, яхшы билгеләр саны белән бәяләнәме?.. Заман технологияләрен белү һәм куллану белән үлчәнәме? Минем бүгенге көндә татар теле һәм әдәбияты укытучысы буларак билгеләнгән максатым, эш юнәлешләрем бар. Алардан башка, заманның барлык яңалыкларын исәпкә алып эшләгәндә дә, эш нәтиҗәлеге турында сүз йөртеп булмый, минемчә. Максатым дөрес билгеләнгән булса, бәлки мин дә осталар сафында булырмын әле...

Мин- татар теле укытучысы... Мин телемнең үзенчәлекләрен, халкымның әдәби, мәдәни мирасын укучыларыма җиткерүче; Туган ил, туган тел, аның бу тормыштагы урыны, башка телләр белән тәэсир итешүе турында сөйләүче; халкымның тарихы буенча мәгълүмат биреп, шул халыкның вәкиле булуыбызга горурлык хисе тәрбияләүче.

Татар халкы Россиядә халык сан бунча икенче урында тора. Без- ерак гасырларны иңләгән дәүләтчелек тарихы булган, борынгы әдәбияты, милли йөзе бар халык. Без- язмыш сынавы белән бөтен дөньяга таралган милләт. Татарстан Республикасы- халкымның йөрәге. Ул һәрчак татар язмышының хәлиткеч үзәге булачак. Шуңа да без, Татарстанда яшәүче татарлар, һәрчак

камиллеккә омтылырга тиеш; телне,  әдәбиятыбызны белүдә, милләт тарихын өйрәнүдә, гореф-гадәтләрне саклауда халкыбыз өчен үрнәк булырга тиеш. Тел һәм әдәбият буенча программада тәкъдим ителгән белем күләменнән тыш, минем укучыларымда әнә шушы хакыйкатьне аңлау булырга тиеш дип исәплим. Ә бу төшенчәләрне җиткерү- һөнәребезнең бернинди тикшерү эше, олимпиадалар да билгели алмый торган юнәлеше. Югарыда әйтелгән кыйммәтләрне билгеләүдәге табышларым түбәндәгеләр...

Беренче табыш. Таныш шартлар, кешеләрне очрату укучыларда һәрчак кызыксыну тудыра. “Туган авыл, як” төшенчәсе укыту материалын конкретлаштыра, иң авыр үзләштерүче балага да мәгълүмат “барып җитү” мөмкинлеген бирә. Һәр авылда, районда тарихның билгеле бер чорында үзен таныткан шәхесләр бар. Аларны белү аша укучы үзе яшәгән төбәкне илнең, халыкның бер өлеше итеп тоя, өйрәнелә торган материал китап сүзе булудан гамәли юнәлешкә күчә. “Ә бу чорда “бездә” нинди күренекле кешеләр яшәгән?”, “Татарлар бу вакыйгада ничек катнашкан?”- укучының белемгә омтылышын әнә шул сораулардан күрергә була.

Икенче табыш. Урбанизация дигән күренеш безнең халыкны да читләтеп үтми. Ә милли үзенчәлекне сакларга кирәк. Казанда эшләгән вакытта мин үзем өчен шундый ачыш ясадым, шәһәрдәге татар баласына “Син кайсы авылдан?” дип сорасаң, ул җавап бирәчәк. Чөнки гаиләнең авыл белән бәйләнеше тыгыз. Мондый балаларның теле хәтта диалектизмнарга да бай. Бу категория шәһәр баласы һәм авыл балалары белән  әдәби телне өйрәтү юнәлешендә эшләргә туры килә. Бистә һәм шәһәр балалары туганнан алып билингвизм шартларында (ә кайберләренең русчасы күпкә өстенлек итә) яшиләр. Бу шартларда телләрне чагыштырып өйрәнү белән шөгыльләнәбез. Теманы сөйләгәндә үз теленнең өстенлеге, мөмкинлекләренә басым ясап күрсәтә белү- инде осталыктан тора. “Татар теле- үзләштерү өчен җиңел тел”, дию генә җитмәс, тәрҗемәдә конструкциянең гадиерәк булуын, синонимик вариантлар күплеген һ.б. даими күрсәтеп тору кирәк. 11нче сыйныф укучысының(рус төркеме) “Татар телен өйрәнү җиңел, чөнки кушымча кушканда тамыр үзгәрми”,- диюе “җиңү” түгелмени?

Рус төркемнәрендә эшләү тәҗрибәм зур түгел әле минем. Шулай да үзем өчен ачкан табышны кулланам. Укучылар өчен чит телне өйрәнгәндә үз телендә дә очрый торган сүзләрне табу әһәмиятле. Соңгы 50-70 ел эчендә рус теле һәм аның аша кергән алынмаларны исәпкә алмасак та, татар телендә рус алынмалары җитәрлек, борынгы чорда кергәннәре элизия үзгәреше кичергән. Башлангыч сыйныф укучысы өчен истә калмый азапланган “арыш”ның

“рожь” булуы “зур ачыш” кына түгел, ә телне өйрәнергә этәргеч тә. Сыйныфымда таҗик балалары да утыра. Татар телендә фарсыдан алынган сүзләргә басым ясау(үзләренеке бит!), гарәп теле сүзләре ике тел өчен ислам дине аша уртак булуын билгеләү, аларга  хәтта психологик яктан уңай шартлар да тудыра. Ә югары сыйныфларда, киресенчә, рус телендәге төрки сүзләргә күбрәк игътибар иттерәм. Минем укучыларыма эчтән генә:” Татар теле дә рус телен баеткан, сез өйрәнә торган тел- бөек ул”,- дигән сүзем бу. “Этимологик сүзлек” бу очракта зур ярдәмче. Ә гомумән алганда,  төрле халык вәкилләрендә бер-берләренә  карата түземлек тәрбияләүне шундый ысул белән дә тормышка ашырам мин.

Халыкның мәкаль-әйтемнәрен кулланып эшләү- минем ачыш түгел. Ләкин ул – зур табыш. Мәсәлән, ”Татарга тылмач кирәкми”,- дигән сүз нәрсәне аңлата? Моны төшендерү- төрки халыклар туганлыгына басым ясау, татар телен белсәң, күп телләр нигезенә төшенәсең, дип әйтү. Моны кабул иткән укучы үз каршында яңа офыклар ача ала.

Сыйныф белән яки электив курсларда эшчәнлектәге табышым: һәр нәрсәне өйрәнүне үзеңнән башлау. Бу- шәҗәрә, гаилә тарихы. Югары сыйныфларга таба юнәлеш ономастик материалны өйрәнүне колачлый. Һәркемнең үз баласына туган авылы, елга, күл, таулары турында сөйләрлек сүзе булырга тиеш! Без, татар теле һәм әдәбияты укытучылары, халкыбыз тарихын балаларга җиткерүдә  мәктәптә иң максатчан эшләүчедер ул. Чөнки уку елы ахырында 10 сәгать эчендә БДИга әзерләүче тарих укытучысының татар халкы тарихын җентекләп өйрәтергә мөмкинлеге юк.

Югарыда телгә алынган табышларымның күбесе бер шартны үтәгәндә эшли:  татар баласы татар телендә аңлаша алу мөмкинлегеннән (һәрдаим!) файдаланырга тиеш, чөнки тел- халыкның яшәеш  нигезе, системасы. Телебезне саклый алсак, балаларыбыз татар булулары белән горурланса, үз балаларына телне өйрәтергә омтылса, тарих белән кызыксынса, без дә “үз һөнәребезнең остасы” исемен йөртергә лаек булырбыз...